**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ________

2025 елның су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ачык сулыкларында су коенуны тыю турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 26.05.2026 ел, 10-26р номерлы «2026 елның су коену сезоны чорында су объектларында гражданнарның иминлеген тәэмин итү турында»гы күрсәтмәсе нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә сулыкларда гражданнарның иминлеген тәэмин итәрлек пляжлар һәм башка оештырылган массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елның су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарга су коенуны тыярга.

2. 2026 елгы су коену сезонында Актаныш муниципаль районының су яны объектларында халыкның күпләп ял итү урыннарында рейдларны профилактикалау өчен мобиль төркем составын расларга (кушымта).

3. 1 июньнән (су коену сезоны башлану белән) су объектлары, шулай ук авыл җирендә урнашкан сулыклар янында гражданнарның массакүләм ял итү урыннарын патрульләү буенча мобиль төркемнәр эшен активлаштырырга;

4. Авыл башкарма комитеты җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- коену сезоны дәвамында җирлек территориясендәге ачык сулыкларда коенуны тыю һәм балаларга аерым контроль кирәклеге турында халыкка аңлату эшләре алып барырга, белешмәлекләр тапшырырга;

- балаларның өлкәннәр ягыннан күзәтүсез һәм караучысыз булган гаиләләрне махсус контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш алып барырга, ата-аналарга имза куйдырып, коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;

- ачык сулыклар янында ике телдә коенуны тыю турында аншлаглар куярга, бу урында коенуны тыю сәбәпләре турында тулы мәгълүмат бирергә (төбенең рельефы, суның биологик составы һ.б.).

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ачык сулыкларында 2024 елның су коену сезоны чорында коенуны тыю турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 02 июнендәге ПР-130 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева

Расланган
Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
________ №____ белән

2026 елгы су коену сезонында Актаныш муниципаль районының су тирәсендәге объектларында халыкның күпләп ял итү урыннарында профилактик рейдлар үткәрү өчен мобиль төркемнәр составы

Кадырова Л.Р. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе секретаре, булдырылган мобиль патруль төркемнәренең эшен тикшереп тору өчен Башкарма комитетның җаваплы вазыйфаи заты;

Садыков Д.Р. - Актаныш янгын-коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча);

Минһаҗев М.Р. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Шакирова Р. М. - ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы (килешү буенча);

Нургалиев И.И. - Актаныш муниципаль районының «Суларда коткару җәмгыяте» региональ иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча);

Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).